Шәймөхәммәтова Алия Мөхәммәтҗан кызы
Лаеш районы Имәнкискә урта мәктәбе директоры,
югары квалификацияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы

**"Татар теле һәм әдәбияты укытучыларының Бөтенроссия күләмендә үткәрелә торган "Туган тел" мастер-класс бәйгесендә мастер-класс**

Чыгышымны бер гыйбарәдән башлыйсым килә. Дәрес. "Сез бүген чәй әзерләү гадәтен өйрәнерсез", - дигән укытучы. Укучыларына чәй әзерләүнең бөтен нечкәлекләре язылган юлламаны биргән дә , үзе табигать кочагына чыгып утырган. Ә шәкертләр укуга чумган, һәркайсы күбрәк өйрәнү, белү теләге белән янган. Күпмедер вакыттан соң укытучы үзләштергән белемнәрнең дәрәҗәсен тикшерә башлаган. Берсен-берсе уздырып укучылар җавап бирергә керешкәннәр.

- Ак торна башын юа. Димәк,  чәйнекне кайнар су белән чайкап алырга, - дигән беренчесе
- Чәйне салырга, - дип дәвам итә икенчесе
- Кайнар су өстәргә, капкачын ябарга , - дип кушыла калганнары.

Тик бер укучы берни дә җавап бирми. Ул чәйнекне ала да, бар шартларга туры китереп, тәмле чәй әзерләп, укытучыны сыйлый. Шул чак укытучы:

- Синең җавабың иң яшысы булды.Син мине шатландырдың, чөнки төп кагыйдәне үзләштергәнсең, - ди. - Укыганыңны сөйләмә, аңлаганыңны сөйлә!

Кемдер түзми:

- Укытучым, ул бит берни эндәшмәде! -  дип ярсый
- Эшләп күрсәткән, гамли  эшнең тавышы сүзләрдән көчлерәк, - ди, елмаеп укытучы.

Укытучы нинди алымнар кулланган?
(мөстәкыйльлек, хезмәттәшлек, практик эшләрнең кыйммәте, кызыксындыру һ.б)
Әлбәттә, укытучының зирәклеге һәм тәҗрибәле булуы күренеп тора.
Мөстәкыйль рәвештә көч түгеп алган белемнәр – иң ныгы
Хезмәттәшлек аша зур җиңүләргә ирешеп була. Заманча әйтсәк интерактив метод
Белемнәр  һәм аларны  тормышта дөрес итеп куллану ассызыклана.

Ничек уйлыйсыз, бүген нәрсә турында сөйләшербез?

Белемнәрне тиешле җирдә (тормышта, яшәештә) тиешле дәрәҗәдә куллана белү, тышкы мохиткә тиз җайлашу, анда аралаша белү, эшләү сәләте Функциональ грамоталылык дип атала.

Бүген мин сезне татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә функциональ белемле шәхес формалаштыру турында фикер алышырга чакырам.

Минем максатым: "Туган (Татар) тел һәм әдәбияты дәресләрендә функциональ грамоталы шәхес формалаштырырга өйрәтү"

Бурычларым:

1. Туган (Татар) теле һәм әдәбияты дәресләрендә функциональ грамоталылыкка ирешү юлларын билгеләү.
2. Туган (Татар) теле һәм әдәбияты дәресләрендә функциональ грамоталылыкка ирешү өчен “этәргечләр” бирү
3. Туган (Татар) теле һәм әдәбияты дәресләрендә функциональ грамоталылыкка ирешү алымнары белән таныштыру.

Иң беренче тапкыр грамоталылык термины 1965 елның 8 сентябрендә ЮНЕСКО тарафыннан Тегеран шәһәрендә мәгариф министрларының Бөтендөнья конгрессында кулланыла. Ул вакытта грамоталылык министрлар каршында гомуми белем белән тәэмин ителгән кешеләр санын арттыру бурычы буларак карала. Димәк, укырга һүм язарга өйрәтү. 2009, 2010 , 2011 елларда функциональ грамоталылык термины белән яңа федераль белем бирү стандартлары гамәлгә кергәч таныштык. Функциональ грамоталылык- универсаль уку гамәлләре формалаштыруның нигезе. Президентыбыз В.В.Путинның мәгариф системасы алдына куйган бурычы барыбызга да мәгълүм. Шуннан чыгып, 2018- 2025 елларга “Мәгариф үсеше” турындагы дәүләт программасы белем бирү сыйфатын PIRLS ( уку, текстны аңлау), TIMSS (төгәл фәннәр), PISA (белем дәрәҗәсен тикшерү) кебек халыкара тикшеренүләрдә лидерлар рәтендә күрсәтүне күздә тота. Быел, 2022 елның беренче сентябрендә яңа ФДС буенча эшли башлаячакбыз.Бу стандартларның таләбе буенча фән буенча көтелгән нәтиҗәләр функциональ грамоталылык нәтиҗәләре белән үрелеп барырга тиеш.

*Функциональ грамоталылык* терминына килгәндә, совет һәм Россия лингвисты, психолог А.А.Леонтьев түбәндәге билгеләмәне бирә: «Функциональ грамоталылык – тормыш бурычларын хәл итү өчен, кешенең гомер дәвамында алган белемнәрен эшчәнлекнең төрле даирәләрендә, аралашуда һәм социаль мөнәсәбәтләрдә куллана белү сәләте ул».

Белгәнебезчә, функциональ грамоталылык күпкырлы төшенчә. Ул уку грамоталылыгын, математик грамоталылыкны, табигый-фәнни грамоталылыкны, финанс грамоталылыгын, глобаль компетенцияләр, креатив фикерләүне үз эченә ала.

Әлбәттә, без, туган тел һәм туган тел әдәбияты укытучылары көнүзәк мәсьәләләрдән читләшә алмыйбыз.

Әйдәгез, *Функциональ грамоталы укучының моделен төзеп карыйк әле.*

- Мөстәкыйль
- Җәмгыятьтә яраклашып яши белүче
- Шәхси сыйфатларга ия булган
- Шәхси осталыкка ия булган
- Информация белән эшли белүче
- Белемле
- Белемнәрен гамәли кулланучы
- Бәяли белүче
- Җаваплы
- Үз сүзен әйтә һәм дәлилли белүче
- Креатив фикерле
- Мәгълүмати технологияләрне куллана белүче
- Югалып калмаучы
- Нәтиҗәләр ясый белүче

Безнең бурыч???

Безнең бурыч- укучыны һәрьяклап үстерү.

Заманча мәктәп - ул укучы тормышының бер өлеше, анда укучы киләчәктә тормыш итәргә дә, җәмгыятьтә яшәргә дә әзерләнергә тиеш. Ул теләсә нинди проблемаларны хәл

итәргә өйрәнергә, мәгълүматны белемгә әйләндерергә, белемнәрне практикада кулланырга өйрәнергә тиеш.

Швецария педагогы Иоганн Генрих Песталоцци әйткәнчә “Укучыларым яналыкларны үзләре табарлар, беркайчан да миннән ишетмәсләр. Минем бурычым-шәкертләремнең шәхси идеяларын ачу һәм үстерергә ярдәм итү.” Көн кадагына суга торган сүзләр. Килешсезме?

Бүгенге цифрлаштыру гасырында укучыларда уку грамоталылыгын үстерү аеруча әһәмияткә ия дип уйлыйм. Белем бирүнең нинди генә предмет өлкәсен алсак та, беренче чиратта, аңлап уку, укылган тексттан кирәкле мәгълүматны аера белү сәләте кирәк. Текст уку ул – белем бирү генә түгел, тәрбияви бурычлар үтәүне дә үз эченә ала. Димәк, шәхеснең рухи-әхлакый сыйфатларын формалаштыруда текст белән эшләүнең роле зур.

Фикерләү процессыны, нигезен – танып белү тәшкил итә. Укучы дәрес материалын танып белгәч кенә, аңлау дәрәҗәсенә күчә. Материалны аңлагач, күнегүләр эшли белә. Һәм иң соңгы этап булып, үзләштерелгән материалны бәяләү булып тора. Дәрестә текст белән эшләүне укучыларга кызыклы да, аңлаешлы да булырлык итеп оештырырга кирәк.

Укучыларда туган (татар) теле һәм әдәбияты дәресләрендә бу максаттан чыгып, төрле алым һәм формаларга таянырга мөмкин.

**Сюжет таблицасы алымы**

Иң гади сорауларга җавап биреп сюжетны билгеләргә өйрәтү

**Сюжет (**Т.Миңнуллин “Авыл эте Акбай”**)**

| **Кем?** | **Нәрсә?** | **Кайчан?** | **Кая?** | **Ни өчен?** |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

**Синтез таблицасы алымы**

Т.Миңнуллин “Авыл эте Акбай” буенча өзекләр тәкъдим ителә. Индивидуаль эш. Таблица тутыралар.

**Т.Миңнуллин “Авыл эте Акбай”. Өзек.**

**Тәмлетамак.** Күңелсез. Иркәләмиләр дә. Хуҗалар: ”Тычкан тот”, - диләр. Тотасым килми минем тычканны. Җирәнәм мин аннан.Фу- фу!!! ...

Шәһәр дигән җирдә рәхәт икән яшәргә.. Тычкан юк, күсе юк. Кулда гына йөртәләр.

Мияу... Акбай, исәнме!

**Акбай.** Һау –һау...Саумы.

**Тәмлетамак.** Акбай, бик зур үтенечем бар. Мине шәһәргә алып бар.

**Акбай.** Нинди шәһәргә?

**Тәмлетамак.** Кешеләр күпләп яши торган урын бар. Телевизордан карадым.

**Акбай.** Миңа монда да яхшы. Менә дигән оям бар. Тамагым тук. Хуҗам миңа әйтә, дус, ди. Кулын биреп күрешә. Сиңа ни җитми? Сөтең алдыңда, урының җылыда.

**Тәмлетамак.** Беләсеңме, Акбай, шәһәрдә этләрне кулда гына күтәреп йөриләр. Шәһәр этләре диванда йоклыйлар.

**Акбай.** Ялганлама, яме.

**Тәмлетамак.** Билләһи, үзем күрдем..

**Акбай.** Кулга күтәргәч, эт этмени ул! (Китә башлый).

**Тәмлетамак.** Акбай, шәһәрне бик күрәсем килә, урамнарында йөрисем килә.

**Акбай.** Ярый, барып кайтырбыз, алайса. (Китәләр).

**Җыелма таблица**

| **Тексттагы төп сүзләр яки сүзтезмәләр** | **Төп сүзләр кергән өзекләр, вакыйгалар** | **Бу фикер ни өчен мөһим? (уйланулар, дәлилләр)** |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

**Т.Миңнуллин “Авыл эте Акбай”. Өзек.**

**Акбай.** Ә нигә урман эченнән үтәргә ярамый?

**Бүре.** Ярамый.Урман безнең йортыбыз.Хәзер анда этләр ияләште. Шәһәрдәге хуҗасыз этләр буталап-буталып йөриләр дә, урманга киләләр.Шуңа ана этләр ата бүреләрнең башларын әйләндерәләр. Шуннан көчекләр табалар. Ә ул көчекләр ни эт түгел, ни көчек түгел. Бүре нәселе корып бара. Ни эт түгел, ни бүре түгел нәмәстәләр урманны басты. Алар эттә акыллы, бүредән усалраклар. Җыен әшәкелекне дә алар кыла. Кешеләр аннары безне гаепли. Безне аталар.Менә шуңа курә, без, бүреләр сакта торабыз. Урманга этләрне кертмибез

**Җыелма таблица**

| Тексттагы төп сүзләр яки сүзтезмәләр | Төп сүзләр кергән өзекләр, вакыйгалар | Бу фикер ни өчен мөһим? (уйланулар, дәлилләр) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

**Т.Миңнуллин "Авыл эте Акбай". Өзек.**

**Дүрткүз.** Бөтен кешеләр дә начар түгел инде.. Минем белән бер малай уйный, ул бик әйбәт.

**Муйнак.** Уйныйлар гына шул, уйныйлар гына. Менә мине дә этнең ни икәнен белмәүче алып кайтты өенә. Иркәләп бозылган малаена уйнарга бирде. Ул малай мине кешеләргә өстереп, кешеләрне таларга өйрәтте. Үзегез уйлап карагыз , колли токымы, безнең токым кайчан да булса, кешеләрне талаганы бармы? Өйрәнергә теләмәгәч, таяк белән кыйнады. Мин түздем, түздем дә качтым. Шуннан бирле качып йөрим.Баштарак тотарга маташтылар - тоттырмадым. Кызыкмасыннар дип, юри пычракта аунадым. Хәзер минем колли дип әйтерлек кыяфәтем дә калмады.

**Дүрткүз.** Бер начар малай аркасында бөтен кешене сүкмиләр инде.

**Муйнак.** Берәү генә түгел андый малайлар. Олылар да шактый. Алар үзләре бит бер начар эт аркасында бөтен этләрне дә.....

**Җыелма таблица**

| Тексттагы төп сүзләр яки сүзтезмәләр | Төп сүзләр кергән өзекләр, вакыйгалар | Бу фикер ни өчен мөһим? (уйланулар, дәлилләр) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |

**Т.Миңнуллин “Авыл эте Акбай”. Өзек.**

**Сарбай.** Әй, туган, мәчегә ияреп йөриме соң инде рәтле эт?

**Акбай.** Без бер йортта яшибез.

**Сарбай.** Алай дисәң генә инде. Әле мәчең кайда соң?

**Акбай.** Анау чормага менеп киткән иде төшми дә , төшми.

**Сарбай.** Чормадан мәче төшәмени, акылсыз?

**Акбай.** Мин бит Тәмлетамакка, көтәм, дип вәгъдә бирдем. Вәгъдәсендә тормаган эт, эт буламыни?

**Сарбай.** Молодец! Хуҗаң яхшы тәрбияләгән.

**Җыелма таблица**

| **Тексттагы төп сүзләр яки сүзтезмәләр** | **Төп сүзләр кергән өзекләр, вакыйгалар** | **Бу фикер ни өчен мөһим? (уйланулар, дәлилләр)** |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

**Т.Миңнуллин “Авыл эте Акбай”. Өзек.**

**Тәмлетамак.** Нәрсә сөйлисең син, нәрсә сөйлиең? Нинди Тәмлетамак булыйм мин сиңа? Мин-Кетти. Мин бит һава суларга гына чыккан идем. Диван өстендә ята-ята арыдым. Хәзер инде мине хуҗам эзлидер. Кэтти кая китте дип җылыйлардыр.

**Акбай.** Тәмлетамака охшаган. Тәмлетамак, син бит бу?

**Тәмлетамак.** Нәрсә сөйлисең син? Нәрсә сөйлисең?Минем сине күргәнем дә юк.Син авыл эте, мин шәһәр мәчесе.

**Сарбай.** Шәһәр мәчесе булгач, аның авыл эте икәнен кайдан белдең?

**Тәмлетамак.** Белми ди сиңа, белми ди .... авыл этен танымыйлар ди...

**Акбай.** Тавышы Тәмлетамакныкына охшаган.

**Тәмлетамак.** Ни сөйлисең син, ни сөйлисең, дурак?

**Акбай.** Тәмлетамак, алдашма инде, син ич бу!

**Тәмлетамак.** Мин – Кэтти. Кэтти! Кэтти.

**Акбай.** Таныйм ич инде, янган мич янында боргаланып йөргәндә койрыгыңа ут капкан иде. Әнә койрык очыңда йонең юк.

**Тәмлетамак.** Булмаса соң, булмаса.....

**Җыелма таблица**

| **Тексттагы төп сүзләр яки сүзтезмәләр** | **Төп сүзләр кергән өзекләр, вакыйгалар** | **Бу фикер ни өчен мөһим? (уйланулар, дәлилләр)** |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

**“Диаманта” “Даймонд ”алымы**

- Энҗе таш — Бриллиант һ.б.
-

Даймонд инглиз теленнән кергән сүз, “бриллиант” дигәнне аңлата. Ул рифмалашмаган җиде юллык шигъри формада язылган кыска әдәби әсәр. Аның ярдәмендә ике төшенчә арасындагы охшаш һәм аермалы якларны билгеләргә мөмкин.

Диамантаны язу тәртибе:

1нче юл. 1 исем (тема).

2нче юл. 2 сыйфат (теманы ачыклау).

3нче юл. 3 фигыль (эш, хәл, хәрәкәт).

4нче юл. 4 исем (ассоциация).

5нче юл.  3 фигыль (капма-каршы эш-хәл,    хәрәкәт)

6нчы юл.  2 сыйфат (капма-каршы теманы ачыклау).

7нче юл.  1 исем (капма-каршы тема).

***НӘТИҖӘ:*** Диаманта алымы иҗади сәләтләрне үстерергә, үз карашыңны булдырырга өйрәтә. Зур күләмле информацияне гомумиләштерергә, катлаулы мәсьәләләрне гадиләштерергә булыша. Диамантны язуның төгәл тәртибе укучының фикерен дөрес формалаштырырга, төп фикерне билгеләргә ярдәм итә. Мондый иҗади эш башкару – җиңел, күңелле, файдалы. Сөйләм теле камилләшә, авыр төшенчәләр үзләштерелә. Һәм иң мөһиме диамант төзү укучыдан, уку материалында иң мөһим элементларны табуны, йомгак ясауны һәм шуны берничә сүз белән (кыска итеп) әйтеп бирүне таләп итә.

**Көтелмәгән сораулар.** Креатиф фикерләүне үстерүгә юнәлә, фантазияләрен баета.

Шәмәхә төстән нинди тәм килә?

Җиде снын сотып карасаң, ничек тоела?

Дүшәмбе көннен формасы нинди?

Әни сүзеннән нинди тәм килә?

**“Ыргытылган таш” алымы.**

***“Ыргытылган таш” алымы. (Прием “Брошеный камень”)***
“Ыргытылган таш” алымының авторы күренекле әкиятче, журналист Дж. Родари.

Тәнкыйди фикерләүне үстерү технологиясенең бу алымы укучыларның иҗади фикерләүләрен үстерә, фантазияләрен баета, предметлар, вакыйга-хәл арасындагы логик бәйләнешне табарга өйрәтә. Шулай ук бу алым аша укучыларның бәйләнешле сөйләм телләре үсә, чөнки инша, хикәя, мәкалә, синквейн язарга әзерләнгәндә лексик берәмлекләр тупларга ярдәм итә.

**Күчтәнәч**

А4 форматында бөтен алымнар тупланган бөкләп ясый торган китапчык бергә фокус төркемдә ясала. Методик кулланма буларак хезмәт итәчәк.

«Функциональ грамоталылык – тормыш бурычларын хәл итү өчен, кешенең гомер дәвамында алган белемнәрен эшчәнлекнең төрле даирәләрендә, аралашуда һәм социаль мөнәсәбәтләрдә куллана белү сәләте ул»

*совет һәм Россия лингвисты, психолог А.А.Леонтьев*

## ФУНКЦИОНАЛЬ ГРАМОТАЛЫЛЫК

- уку грамоталылыгы
- математик грамоталылык
- табигый-фәнни грамоталылык
- финанс грамоталылыгы
- глобаль компетенцияләр
- креатив фикерләү

**“Ыргытылган таш” алымын үткәрү методикасы:**

- Тема буенча укытучы тарафыннан бер сүз бирелә. Укучылар бирелгән сүзгә төрле эпитетлар, ассоциатив сүзләр һ.б. әйтеп чыгалар. Бу очракта бирелгән сүз суга ыргытылган таш, ә укучылар әйткән сүзләр суда барлыкка килгән түгәрәк боҗралар булып күзаллана.
- Барлык әйтелгән сүзләрнең тема белән бәйләнеше анализлана, иҗади эш өчен кирәклеләре генә сайланып алына.



































